**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Түбәндәге затларны Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары итеп расларга:

Бәһаутдинова Наилә Гомәр кызы – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Идарә, икътисад һәм финанслар институты директоры;

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе;

Вәлиева Әлфия Фуат кызы – «АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фонды директоры;

Гайнетдинов Азат Галимҗан улы – «Социаль яраклашуга һәм хокукларны торгызуга ярдәм итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры;

Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улы – «Спорткультавтотовары» акционер җәмгыяте генераль директоры;

Кабыш Евгений Григорьевич – «Әфганстан ветераннарының Россия берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы рәисе;

Какохо Тимур Геннадиевич – «Россия юристлар ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе Башкарма комитеты рәисе;

Крюкова Мария Викторовна – «Татарстан Республикасы яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «УРАМ» яшьләр экстрим-паркы директоры;

Мөбарәкшина Анна Вячеславовна – «Без бергә» авыр тормыш шартларында калган кешеләргә ярдәм итү фонды директоры, «Медиклар-волонтерлар» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлекчәсе төбәк координаторы;

Патеев Ринат Фаикъ улы – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Исламны өйрәнү үзәге» аерымланган структур бүлекчәсе директоры;

Сабитова Наталья Михайловна – «Татарстан Республикасының мордва милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе;

Самойленко Владимир Михайлович – «Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе Казан православие дини семинариясе» дини оешмасы – дини югары белем бирү мәгариф оешмасы ректоры;

Скобельцына Елена Германовна – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф югары белем бирү учреждениесенең «Н.И. Лобачевский исемендәге лицей» гомуми белем бирү мәктәп-интернаты директоры;

Софронов Алексей Николаевич – Татарстан Республикасының «Универсаль көрәш» спорт федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасы төбәк бүлекчәсе президенты;

Тимирясова Асия Виталий кызы – «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе ректоры;

Фәтхуллина Эльмира Вадимовна – «Россия Федерациясе Театр әһелләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия иҗтимагый оешмасы бүлекчәсе – Татарстан Республикасы Театр әһелләре берлеге рәисе урынбасары;

Хәсәнов Илфар хәзрәт (Хәсәнов Илфар Ренат улы) – Татарстан Республикасы мөфтиенең беренче урынбасары;

Шакиров Данис Фәнис улы – «Бөтендөнья татар конгрессы» төбәкара иҗтимагый оешмасы Башкарма комитеты рәисе;

Шакирҗанов Рафаэль Мәҗит улы – «МЭЛТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең тышкы икътисадый эшчәнлек буенча киңәшчесе;

Яруллин Тәбрис Мөдәррис улы – «Татарстан Республикасының Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры урынбасары.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 15 декабрь
№ ПУ-877